**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Сукаеш авыл җирлеге Советы КАРАРЫ**

Зур Сукаеш авылы № 5 "05"апрель 2023 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Советының 2020 елның 15 июнендәге 14 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлегенең депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән өчен, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында карар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

**Сукаеш** авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Советының 2020 елның 15 июнендәге 14 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлегенең депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән өчен, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында карар кабул итү тәртибенең 3 пунктндагы ике абзацында, 4 пунктында, 5 пунктындагы ике абзацында, 6 пунктындагы беренче абзацында, беренче абзацында, 7 пунктындагы өченче, 11 пунктындагы беренче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен тиешле килешләрдә «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырып үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда веб-адрес буенча: http://pravo. tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль

районының “Интернет” мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтында веб-адрес буенча: http://aznakayevo. tatar.ru урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны йөкләргә Законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә.

Рәис З.Җ.Закирова